**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 24** **22.03.2021 ел**

**«Җир салымы турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 134 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Урсай авыл җирлеге Уставының 32 статьясына таянып, Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җир салымы турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 134 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 12 сентябрендәге 169 номерлы, 2017 елның 18 октябрендәге 81 номерлы, 2018 елның 16 мартындагы 99 номерлы, 27.11.2020 елның 27 ноябрендәге 12 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4.2.6 пунктчасы белән тулыландырырга:

«4.2.6. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы – чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана торган гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата»;

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Н.А.Гатина**